**Яз килә, яз килә**

1) Елгада боз китү белән,
Җылы көннәр җитү белән,
Карлар эреп бетү белән,
Яз килә, яз килә!

2) Йомшак, нәфис җиле белән,
Зифа, нечкә биле белән,
Яшел чирәм җире белән,
Яз килә, яз килә!

3) Сыерчыклар шавы белән,
Кыр казлары явы белән,
Бәхет-шатлык тавы белән,
Яз килә, яз килә!

4) Гөлчәчәкләргә күмелеп,
Яз килә, нурга төренеп,
Каршы алыгыз йөгереп –
Яз килә, яз килә!